КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 август г.Казань № 1029

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе исемен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» 2012 ел, 2 октябрь, 818 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 16 октябрь, 763 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе исемен «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе итеп үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе исемен «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе итеп үзгәртергә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе уставына;

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсенә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» 2012 ел, 2 октябрь, 818 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 16 октябрь, 763 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «дәүләт бюджет учреждениесе турында» сүзләрен «дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

икенче абзацта «дәүләт бюджет учреждениесен» сүзләрен «дәүләт фәнни бюджет учреждениесен» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән» сүзләренә алмаштырырга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин